**Разил ВӘЛИЕВ,**
*язучы, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе,*
*1981-1984 елларда Чаллы Язучылар оешмасының*
*җаваплы секретаре*

## КАНАТЛЫ АТ СЫНАТМАС

...КАМАЗның беренче нигез ташыннан башлап беренче автомобиленә кадәр араны үз күзләре белән күреп, үз йөрәкләре аша үткәреп яшәгән кешеләр өчен Яр Чаллы сүзе аерата зур мәгънәгә ия, аерата кадерле.

Кешеләрнең рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү нисбәтеннән шәһәрдә искиткеч зур эшләр башкарылды. Шулар арасыннан безгә иң якын торганы – Чаллы Язучылар оешмасы – әдәбият-сәнгать әһелләренең беренче профессиональ оешмасы ачылу булды.

КАМАЗ төзелә башлауга, Яр Чаллыга, йөзләгән профессия кешеләре белән бергә, илнең бөтен почмакларыннан романтик күңелле, шагыйрь җанлы кешеләр дә җыйналды. Мөдәррис Әгъләмов, Хәниф Хөснуллин, Сәлимә Шәрипова, Мөслах Таҗи, Рафис Хисамиев кебек өч дистәгә якын шагыйрь һәм прозаикны туплаган әдәби берләшмәгә Мәхмүт Газизов, Равил Вәлиев, Газиз Кашапов, Равил Лотфуллин, Рәшит Бәшәров, Рафис Сәлимҗанов, Ямаш Игәнәй һәм тагын дистәләгән яшь иҗат көчләре килеп кушылды. «Ләйсән» берләшмәсе оешты.

Чаллы Язучылар оешмасының төп бурычы – әдәби көчләрне бер тирәгә, бер гвардиягә туплап, аларга юнәлеш бирү, бергәләп әлегә теш үтмәгән проблемаларны аңларга һәм, йөрәк аша үткәреп, кешеләргә аңлатырга омтылу, яшь иҗат көчләренә үз юлларын табарга булышу һәм халык белән әдәбият-сәнгать әһелләре арасындагы элемтәне ныгытудан гыйбарәт. Инде әйткәнемчә, КАМАЗда әдәбият көчләренең зур армиясе тупланган. Анда унбер СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Түбән Камада, Алабуга, Зәй, Минзәлә шәһәрендәге әдәби берләшмәләрне дә кушып санаганда, ике йөздән артык яшь әдип иҗат итә.

КАМАЗ темпы белән эшләп, КАМАЗ масштаблары белән фикер йөрткәндә, һичшиксез, Чаллы язучылары да озакламый ил күгенә күренерлек әсәрләр иҗат итәрләр, дип ышанырга ныклы нигез бар.

*Язмышлар яңарганда: хикәяләр, нәсерләр, очерклар, мәзәкләр җыентыгы / Төз.: Эдуард Касыймов һәм Равил Вәлиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – Б. 3-5.*